**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

№ 128 30.10.2018 ел

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»**
**2014 елның 14 ноябрендәге**
**167 номерлы Зәй муниципаль районының**
**Дърт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 32 бүлеге нигезендә, шулай ук "Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 167 номерлы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 11 сентябрендәге 207 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 2 пунктчада «фатирлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктчада «торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә.

1.2. 3 пунктчасында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе** **Р.Т.Ситдыйков**